| ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2017 Казан ш. № 3-8/э

«Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2018 елга хосусый тарифлар билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны дәвамлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр буенча календарь буенча бүленгән хосусый тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, «Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2018 елга зарури тулай табышын (югалтуларны исәпкә алмыйча) билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
08.12.2017 № 3-8/э карарына
1 нче кушымта

«Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән хосусый тарифлар

| № п/п | Челтәр оешмаларының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик сарыф (югалтулар) өчен түләү ставкасы | | электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик сарыф (югалтулар) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2018 | 323 448,63 | 156,47 | 0,94863 | 323 448,63 | 162,73 | 0,95489 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 08.12.2017 № 3-8/э карарына 2 нче кушымта

«Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең
2018 елга зарури тулай табышы
(сарыфларга түләүне исәпкә алмыйча)

| № п/п | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1 | «Экострой Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2018 | 10 378,82 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге